КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 апрель г.Казань № 370

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларын норматив буенча финанслау турында» 2017 ел, 8 август, 566 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 27 июль, 605 нче, 2018 ел, 13 ноябрь, 996 нчы; 2018 ел, 3 декабрь, 1077 нче; 2019 ел, 28 декабрь, 1232 нче, 2020 ел, 3 сентябрь, 785 нче, 2022 ел, 5 февраль, 92 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе турындагы нигезләмәдә:

1.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә, башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны тормышка ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе турындагы нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) мәктәпкәчә белем бирүнең, башлангыч гомуми белем бирүнең, төп гомуми белем бирүнең, урта гомуми белемнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар, озайтылган көн төркемендә укучыларның булуын оештыруга норматив чыгымнар һәм гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга

норматив чыгымнар, дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар формалаштыру тәртибен билгели.»;

1.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар - ул федераль дәүләт белем бирү стандартлары нигезендә гомуми белем бирү оешмасында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен дәреслекләр белән тәэмин итүгә кирәкле финанс чараларының минималь рөхсәт ителгән күләме.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Төп гомуми белем бирү программаларын һәм мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар, озайтылган көн төркемендә балаларның булуын оештыруга норматив чыгымнар, гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар ел саен Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Төп гомуми белем бирү программаларын һәм мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар, озайтылган көн төркемендә балаларның булуын оештыруга норматив чыгымнар, гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар зурлыгы гражданнарга күрсәтелә торган мәгариф хезмәтенең гарантияләнгән минималь бәясе сыйфатында була һәм Татарстан Республикасы бюджетын һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларын формалаштырганда мәҗбүри кулланылырга тиеш.»;

1.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Төп гомуми белем бирү программаларын һәм мәктәпкәчә белем бирүнең мәгариф программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар, озайтылган көн төркемендә балаларның булуын оештыруга норматив чыгымнар, гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар елына бер укучыга исәпләп билгеләнә. Аз комплектлы гомуми белем бирү оешмасы өчен төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар елга класс-комплектка исәпләп билгеләнә.»;

1.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.8. Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар, өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар гомуми белем дәрәҗәләре буенча дифференциацияләнә:»;

түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

«6. Дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе

6.1. Дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә

ашырганда файдалануга тәкъдим ителгән дәреслекләрне сатып алуга чыгымнарны үз эченә ала.

6.2. Бер укучыга исәпләгәндә дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар$N_{d_{uch}}$ түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$N_{d_{uch}} = N_{uch} \times C_{uch},$$

монда:

$N_{uch}$ - башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем программалары буенча укучыларны дәреслекләрнең башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан дәүләт аккредитациясе булган уку-укыту программаларын гамәлгә ашырганда файдалануга кертелгән федераль исемлеге нигезендә дәреслекләр белән тәэмин итү нормасы, дәреслекләрне эксплуатацияләүнең 5 елга тигез уртача срогын исәпкә алып;

$C_{uch}$ - чираттагы финанс елына Татарстан Республикасы бюджетын формалаштырганда кулланыла торган индекслар-дефляторларны исәпкә алып, план елына кадәрге елның 1 сентябре хәленә карата уртача базар кыйммәте нигезендә кабул ителә торган дәреслекләр бәясе.»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларын финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибендә:

2.1 пунктның икенче абзацында «һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә» сүзләрен өстәргә;

2.2 пунктның бишенче абзацында «һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә» сүзләрен өстәргә;

2.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Мәктәпкәчә белем , башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирүнең (төп гомуми белем бирү программалары), өстәмә гомуми белем бирү программалары федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыруга, озайтылган көн төркемендә укучыларның булуын оештыруга һәм дәреслекләр белән тәэмин итүгә финанс белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча $FOSC^{t}_{fgos}$ билгеләнә:

$$FOSC^{t}_{fgos} = \sum_{p=1}^{m} (j_{ip} \times N^{t}_{sdpf_{gos}} + k_{max} \times \left(j_{i_{fact}} - j^{t}_{i_{norm}}\right) \times N^{t}_{sdpf_{gos}} + k_{min} \times \left(j^{t}_{i_{norm}} - j_{i_{fact}}\right) \times$$
$$\times N^{t}_{sdpf_{gos}} + j_{i_{fact}} \times N_{d_{uch}} + j_{i_{ddo}} \times N^{t}_{ddo} + j_{i_{gpd}} \times N^{t}_{gpd} + FOSC^{t}_{fgos_{doy}} + N^{t}_{sdpf_{ink}} \times K_{k}),$$

монда:

$j_{ip}$ - i гомуми белем бирү оешмасында норматив тулыландыру чикләрендә сыйныфларда белем алучылар саны (аз комплектлы мәктәпләр өчен сыйнфый-комплектлар);

$N^{t}_{sdpf_{gos}}$ - гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар;

$k_{max}$ - сыйныфларда белем алучыларның факттагы саны сыйныфларда укучыларның норматив санынннан арткан очракта кулланыла торган 0,2 тигез кабул ителә торган тәгаенләүче коэффициент;

$j_{i_{fact}}$ - i-гомуми белем бирү оешмасы сыйныфларында укучыларның факттагы саны;

$j^{t}_{i_{norm}}$ - сыйныфларда укучыларның норматив саны;

$k_{min}$ - сыйныфларда укучыларның норматив санына җитмәгән очракта кулланыла торган, 0,5 тигез итеп кабул ителә торган тәгаенләүче коэффициент;

$N_{d_{uch}}$ - дәреслекләр белән тәэмин итүгә норматив чыгымнар;

$j_{i_{ddo}}$ - i-гомуми белем бирү оешмасының өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар саны;

$N^{t}_{ddo}$ - гомуми белем бирү оешмаларында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар;

$j_{i_{gpd}}$ - i-гомуми белем бирү оешмасының озынайтылган көн төркемендә укучылар саны;

$N^{t}_{gpd}$ - гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның озайтылган көн төркемендә булуын оештыруга норматив чыгымнар;

$FOSC^{t}_{fgos_{doy}}$ - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Муниципаль мәктәпкәчә мәгариф оешмалары эшчәнлеген норматив финанслау турында" 2019 ел, 02 июль, 546 нчы карары белән расланган Муниципаль мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында һәркем алырлык һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны тормышка ашыруга дәүләт гарантияләрен тәэмин итү өчен норматив чыгымнарны исәпләп чыгару тәртибе нигезендә билгеләнә торган мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартын гамәлгә ашыруга финанс белән тәэмин итү күләме;

$N^{t}_{sdpf_{ink}}$ - гомуми белем бирү оешмаларында инклюзив белем бирүне оештыру юлы белән сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән һәм акылга зәгыйфь укучылар өчен башлангыч гомуми белем бирүнең уку-укыту программаларын гамәлгә ашыруга норматив чыгымнар;

$K_k$ - инклюзив белем бирү гамәлгә ашырыла торган гомуми белем бирү оешмаларында сыйнфый-комплектлар саны;

t - гомуми белем бирү оешмасының территориаль дислокациясе;

p - мәгариф профиле;

m - профильләр саны».

2. Әлеге карар 2023 елга һәм 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджетыннан башлап, Татарстан Республикасы бюджетын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин